КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

БОЕРЫК

2023 елның 17 июле, № 136-п

Коррупция фактлары турында «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау хакында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Коррупция фактлары турында «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – Агентлык) кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

коррупция фактлары турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, кадрлар бүлеге һәм юридик сектор катнашында, Агентлыкта коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла;

коррупция фактлары турында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар эш өчен кирәкле мәгълүматның һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2023 елның 17 июлендәге 136-п номерлы боерыгы белән расланды.

Коррупция фактлары турында «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы таләпләрен үтәү максатында эшләнде һәм Татарстан Республикасы Агентлыгында (алга таба – Агентлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфалары булмаган вазыйфалар били торган хезмәткәрләр (алга таба – хезмәткәрләр) тарафыннан коррупция һәм янау фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, хезмәт тәртибе таләпләрен бозу, шулай ук хезмәт урыныннан явыз нияттә файдалану билгеләрен үз эченә алган башка гамәлләр кылу фактлары турында гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгать) карау үзенчәлекләрен билгели. Башка затлар турында шундый ук фактлар бәян ителгән мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 өлеше нигезендә тиешле органга яисә вазыйфасына мөрәҗәгатьтә телгә алынган мәсьәләләрне карау кертелгән вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

Мөрәҗәгатьтә хокукка каршы әзерләнә, кылына торган яисә кылынган гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать, компетенцияләренә карап, хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

3. Мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып ике эш көненнән артмаган срокта «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә кадрлар бүлеге тарафыннан хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүе уздыру оештырыла (хезмәткәрдән язмача аңлатмалар алына).

4. Коррупция билгеләре булу турындагы мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар расланган очракта, хезмәт тикшерүе уздырган комиссия бәяләмәсе нигезендә җитәкче (аның вазыйфаларын башкаручы зат) күрсәтелгән бәяләмә алган көннән алып өч эш көне эчендә Агентлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә тәкъдимнәр кертә. Тиешле фактлар расланган очракта, хезмәткәргә карата, аның язма аңлатмаларын анализлаудан чыгып, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында мәсьәлә хәл ителә.

Әгәр хезмәт тикшерүе , шулай ук хезмәткәрнең язма аңлатмаларын анализлау нәтиҗәләре буенча хокукка каршы гамәлләрнең әзерләнүе, башкарылуы яисә башкарылган булуы ачыкланса, шулай ук аны әзерли торган, башкаручы яисә башкарган зат турында билгеле булса, тиешле мәгълүмат әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта, компетенцияләренә карап, хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

5. Мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга җавап әзерләү Агентлыкта коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агентлыкның Кадрлар бүлеге, шулай ук юридик секторы, җавапны гражданга җибәрү срогы тәмамланганчы 15 көннән дә соңга калмыйча, Агентлыкта коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка ведомствоара электрон документлар әйләнешенең бердәм системасы ярдәмендә мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча язма тәкъдимнәр җибәрә.

6. Мөрәҗәгатьтә Агентлыкта коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка карата коррупция фактлары турында белешмәләр булган очракта, ул мөрәҗәгатьне карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгать кадрлар бүлегендә, шулай ук агентлыкның юридик секторында карала.